# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Күрәз торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

06.04.2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2024 елның 26 мартындагы 1 номерлы 2023 елның 21 ноябрендәге
1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Күрәз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 21 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Күрәз авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында карары нигезендә **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2023 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Күрәз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 21 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Күрәз авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертергә һәм чараларны түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) Күрәз авылы Яшел урамында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эш өчен түләү), Күрәз авылында юлларны кардан чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Күрәз авылында 1 (бер) данә скважина өчен тирәнлек насосы сатып алу);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын койма белән тотып алу өчен материаллар сатып алу, Күрәз авылында);

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, 10 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru “Песәй авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы ____________ В.И.Мөхәмәтгалеев
(имза) (имза аңлатмасы)